РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» декабрь 2018 ел г. Альметьевск №176

Әлмәт муниципаль районы башлыгының
«Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районында гадәттән тыш
хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча
территориаль ярдәмче системасының
җирле звеносы» турындагы
6 май 2016 ел № 34 карарына үзгәрешләр
кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел 10 ноябрь № 480 карары белән расланган «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел 1 сентябрь №742 карары нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

КАРАР БИРӘМ:

1. Әлмәт муниципаль районы башлыгының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының җирле звеносы» турындагы 6 май 2016 ел № 34 карарына (Әлмәт муниципаль районы башлыгының 2017 ел 8 февраль №25, 2017 ел 26 май №78, 2017 ел 26 сентябрь №163, 2018 ел 30 январь № 6 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

№ 1 кушымтада:

24 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«халыкка гадәттән тыш хәлләр, аларның параметрлары, масштаблары турында мәгълүмат бирү, шулай ук халыкның һәм территорияләрнең

иминлеген тәэмин итү буенча күрелә торган факторлары, гадәттән тыш хәл зонасында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм кабул итү чаралары, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм зыян күрүчеләрне социаль яклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә югалган документларны торгызу тәртибе турында Россия Федерациясе законнарында каралган түләүләрне алу хокукы турында».

№ 3 кушымтада:

комиссия составына кертергә:

Ф.М. Шәрәфиевны - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Әлмәт муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе (килешү буенча);

комиссия составыннан чыгарырга: Н.М. Усмановны;

комиссия әгъзалары вазифаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

С.В. Лаптева – район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

А.А. Әхмәтшин – «Татарстан Республикасы буенча янгынга каршы 11нче федераль хезмәт отряды» федераль дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча);

И.В. Хәйруллина – кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы Әлмәт, Зәй, Лениногорск, Сарман районнары буенча территориаль бүлеге җитәкчесе (килешү буенча).

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфановка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы
вазифаларын башкаручы А.А.Зимин

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ